ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УРСАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРСАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ул .Центральная, д.5, с. Урсаево,
Заинский район, 423535

Центральная урамы, 5 нче йорт,
Урсай авылы, Зәй районы, 423535

Телефон, факс 2-80-46.

Электронный адрес: Ursaev.zai@tatar.ru, сайт: http://zainsk.tatarstan.ru/rus/ursaevskoe.htm

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**30.10.2025 ел.** **№ 19**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районының
Урсай авыл җирлеге территориясендә
велосипедларны, индивидуаль мобильлек чараларын,
төрле спорт инвентарен кую һәм (яисә)
саклау өчен билгеләнгән вакытлыча корылмаларны
һәм (яисә) вакытлыча конструкцияләрне
урнаштыру урыннары һәм схемалары
исемлеген раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштырыла ала торган объектлар төрләре исемлеген раслау турында " 03.12.2014 ел, № 1300 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектларны җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар, гавами сервитут билгеләмичә урнаштыру тәртибен һәм шартларын раслау турында " 2015 елның 5 июнендәге 416 номерлы карары белән Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге территориясендә шундый корылмалар һәм (яисә) конструкцияләр чикләрендә велосипедларны, индивидуаль мобильлек чараларын, төрле спорт инвентарен куюю һәм (яисә) саклау өчен билгеләнгән вакытлы корылмаларны һәм (яисә) вакытлы конструкцияләрне урнаштыру урыннары һәм схемалары исемлеген кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре»бүлегендә урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.Ә. Гатина**

Зәй муниципаль районы
Урсай авыл җирлеге
башкарма комитетының
«30» октябрдә 2025ел
номерлы карарына
19 нче кушымта

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге территориясендә шундый корылмалар һәм (яисә) конструкцияләр чикләрендә велосипедларны, индивидуаль мобильлек чараларын, төрле спорт инвентарен кую һәм (яисә) саклау өчен билгеләнгән вакытлы корылмаларны һәм (яисә) вакытлы конструкцияләрне урнаштыру урыннары һәм схемалары исемлеген кушымта нигезендә расларга

| N | Объектның урнашу урыны | Площадь объекта кв. м | объект төре | Объектның урнашу координаталары |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| 1. | Зәй районы, Урсай авылы, Үзәк ур., 5 й. , Урсай мәдәният йорты | 6 | Урсай мәдәният йорты | 55.095047, 52.241159 |